ГЛАВА ШАДЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.18, с. Шадчи,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422145

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШӘДЧЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшьләр ур., 18 нче йорт, Шәдче авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422145

тел.(факс): (85563) 2-52-24; e-mail: Shad.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар Постановление

“05 ” ноябрь 2019 ел. № 9

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенең Иске Мочалкино авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Шәдче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Иске Мочалкино авылы , Овражная урамы , 27 нче йорт адресы буенча урнашкан Иске Мочалкино авыл клубы бинасында 2019 елның 19 нчы ноябре 13.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенең Иске Мочалкино авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенең Иске Мочалкино авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Иске Мочалкино авылы торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар сатып алу, иске су торбаларын алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Иске Мочалкино авылы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге башкарма комитетына Иске Мочалкино авылы торак пункытында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл җирлеге башлыгы: В.В.Шрыков